**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Чуаш-Кичүе авыл җирлеге башкарма комитеты**
**КАРАРЫ**

2015 елның 1 апреле 8 №

2015 елга Әлки муниципаль районы Чуаш-Кичүе
авыл җирлегендә коррупциягә
каршы тору буенча чаралар планын раслау турында

2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законны, Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 11 апрелендәге «2014-2015 елларга коррупциягә каршы көрәшнең милли планы турында» 226 номерлы Әмерен үтәү йөзеннән Әлки муниципаль районының Чуаш-Кичүе авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. 2015 елга Әлки муниципаль районы Чуаш-Кичүе авыл җирлегендә коррупциягә каршы тору буенча чаралар планын (1-нче кушымта) расларга.
2. Әлки муниципаль районы Чуаш-Кичүе авыл җирлеге Башкарма комитеты сәркатибына План үтәлешенә квартал саен мониторинг ясарга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш-Кичүе авыл җирлеге стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әлки муниципаль районы
Чуаш-Кичүе авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе: Н.Р.Закирова

Әлки муниципаль районының Чуаш-
Кичүе авыл җирлеге Башкарма комитетының
2015 елның 1 апрелендәге 8
номерлы карарына кушымта

**2015 елга Әлки муниципаль районы Чуаш-Кичүе авыл җирлегендә коррупциягә каршы тору буенча чаралар планы**

| № т/б | Чаралар | Үтәү вакыты | Башкаручылар |
|---|---|---|---|
| | **1. Коррупциягә каршы көрәшкә юнәлдерелгән хокук һәм оештыру чараларын тәэмин итү,** | | |
| 1.1. | Федераль һәм республика законнарын үтәү йөзеннән һәм Татарстан Республикасында гамәлдәге коррупциягә каршы нормаларны куллану практикасын гомумиләштерү нигезендә коррупциягә каршы көрәш турында муниципаль норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү | Ел дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе, Башкарма комитет сәркатибы |
| 1.2 | Муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне вакытында бирүен тикшерү | 2015елның 30 апреленә кадәр. | Әлки муниципаль районы Чуаш-Кичүе авыл җирлеге, Башкарма комитеты җитәкчесе |
| 1.3 | Муниципаль хезмәт турында, коррупциягә каршы тору хакында законнарның таләпләрен үтәп, хезмәткәрләрнең, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү:<br>муниципаль хезмәткәрләрнең;<br>муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның | 2015 елның 2 кварталы | Әлки муниципаль районы Чуаш-Кичүе авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе |
| 1.4 | Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт турындагы законнарда каралган чикләү һәм тыюларның үтәлешенә тикшерү үткәрү | Ел дәвамында | Әлки муниципаль районы Чуаш-Кичүе авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе |
| 1.5 | Законнар нигезендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти | 2015 елның 2 кварталы | Әлки муниципаль районының Чуаш-Кичүе авыл җирлеге |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне законнарда билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә урнаштыру. | | Башкарма комитеты җитәкчесе |
| **2. Җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә иҗтимагый контроль механизмнарын булдыру, кире элемтә системасын билгеләү җирле үзидарә органнары эшчәнлеге өчен, кире элемтә системасын билгеләү** | | | |
| 2.1 | Чуаш-Кичүе авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлегендә коррупция фактлары турында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау сроклары һәм нәтиҗәләренә анализ ясау | квартал саен | Башкарма комитет сәркатибы |
| 2.2 | Законнарда билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында район сайтында законнар нигезендә белешмәләр урнаштыру | 2015 елның 2 кварталы | Әлки муниципаль районы Чуаш-Кичүе авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе |
| 2.3 | Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә Чуаш-Кичүе авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге һәм ачыклыгын тәэмин итү | Ел дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе, Башкарма комитет сәркатибы |
| **3.Норматив хокукый актлар һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза актлар һәм аларның проектлары** | | | |
| 3.1 | Норматив хокукый актлар һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен Әлки муниципаль районы Советына бирү | Ел дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе, Башкарма комитет сәркатибы |
| **4. Муниципаль ихтыяҗлар өчен заказлар урнаштырганда коррупциягә каршы тору** | | | |
| 4.1 | 2013 елның 05 апрелендәге «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 44-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренең үтәлешен тикшереп торуны тәэмин итү | Даими | Башкарма комитет җитәкчесе |